КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 декабрь г.Казань № 1199

2026 елга «Социаль эш белән тәэмин итүне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм «Социаль эш белән тәэмин итүне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрдагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплексны булышлык күрсәтеп тору концепциясен раслау турында» 2022 ел, 14 ноябрь, 1208 нче карары белән расланган 2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрдагы бозылышлары һәм башка менталь бозылышлары булган кешеләргә комплексны булышлык күрсәтеп тору концепциясен гамәлгә ашыру максаталрында һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны социаль эш белән тәэмин итүне оештыруның якынча тәртибен раслау турында» 2023 елның 28 июлендәге 605н номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2026 елга «Социаль эш белән тәэмин итүне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны бер сәгатькә 78,19 сум күләмендә;

2026 елга «Социаль эш белән тәэмин итүне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә финанслауның җан башына нормативы бер сәгатькә 78,19 сум күләмендә.

2. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин